КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРКӘҮЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

21 февраль 2019 года № 6

Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2014нче елның 14нче мартында 08 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 30нчы октябрендәге 387- ФЗ номерлы “Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 2нче һәм 28нче матдәләренә үзгәрешләр кертү хакындагы” Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2014нче елның 14нче мартында 08нче номерлы карары (2016 нчы елның 15 апрелендә 13 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирелегенең муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында “хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләрен “комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зайнутдинов